**Республика Татарстан**
**Сармановский муниципальный район Карашай Сакловское сельское поселение**
**423378 ул.Ленина д.100 с.Карашай Саклово Телефон: 885559 4-92-18**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай Саклау авыл жирлеге**
**423378 ,Карашай Саклау авылы, Ленин ур.100 йорты Телефон: 885559 4-92-18**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
« 02 » ноябрь 2023 ел № 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Чураш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Уставы: 1.Чураш авылы мәдәният йорты бинасында, гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 16 нояберенә 11 сәгать 00 минутта билгеләргә

2.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:«I группа инвалидлар , көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, 2024елда 600 сум үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкаруга тоту белән килешәсезме:

1. Чураш авылынлагы урамнарны яктырту җайланмасы (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру);

2. Чураш торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү максатында су өчен савытлар сатып алу ;

3. Юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне урап узу, Чураш торак пункты зиратына керү юлын ремонтлау (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, запас часть)

4. Чураш торак пункты паркының коймасын тоту

«ӘЙЕ» «ЮК?».

3.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, Чураш авылы торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Карашай-Саклау Советы Башлыгы

авыл җирлеге Башлыгы В. В. Хөсниева